ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының $28^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 47-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының $28^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 47-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 203-VII ДС

47-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш),№ 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «нефть продуктлары үткәргечләрнең,» сүзләреннән соң «нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргечләрнең,» сүзләрен өстәргә;
2) 1 пунктта «нефть продуктлары үткәргечләрнең,» сүзләреннән соң «нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргечләрнең,» сүзләрен өстәргә;
3) 2 пунктта «нефть продуктлары үткәргечләрне,» сүзләреннән соң «нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргечләрне,» сүзләрен өстәргә;
4) 4 пунктта «яисә нефть продуктлары үткәргеч» сүзләрен «, нефть продуктлары үткәргеч, нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргеч яисә аммиак үткәргеч» сүзләрен өстәргә, «нефть продуктлары үткәргечләргә,» сүзләреннән соң «нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргечләргә,» сүзләрен өстәргә;

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану турында» 2024 елның 26 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Җир кодексына территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү, үзгәртү һәм аларның гамәлдә булуын туктату мәсьәләләрен җайга салуга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда, торба үткәргечләрнең саклау зоналары билгеләнә торган объектлар исемлегенә нефть һәм газ эшкәртү продуктлары өчен торба үткәргечләр керә дип төгәлләштерелә.

Закон проекты белән федераль законнардагы бу үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Җир кодексында да чагылдыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының $28^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасы Җир кодексының $28^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 28[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.